| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЬМЕТЬЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘЛМӘТ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» ноября 2021 ел г. Альметьевск № 1689

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2020, 2021, 2022 елларга Әлмәт муниципаль районында урнашкан күпфатирлы йортларның гомуми мөлкәтен капиталь ремонтлау буенча региональ программаның кыска сроклы планын раслау турында» 2019 елның 2 декабрендәге 2092 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законны, «Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 14 ноябрендәге УП-611 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2020 елның 9 октябрендәге 01-09-13820 номерлы хаты, «2020, 2021 елларга күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаның кыска сроклы планына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 19 октябрендәге 01-09-14286 номерлы үтәү йөзеннән

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2020, 2021, 2022 елларга Әлмәт муниципаль районында урнашкан күпфатирлы йортларның гомуми мөлкәтен капиталь ремонтлау буенча региональ программаның кыска сроклы планын раслау турында» 2019 елның 2 декабрендәге 2092 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 10 мартындагы 324 номерлы, 2020 елның 13 ноябрендәге 1663 номерлы, 2021 елның 2 апрелендәге 451 номерлы, 2021 елның 28 октябрендәге 1504 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарга 3 нче кушымтада:

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. 2022 елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау күләмнәре

Зак. № 305-2000

Табл.№1

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге: | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме (данә) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| җылылык белән тәэмин итү | п.м. | 5 136,00 |
| электр белән тәэмин итү | п.м | 20 894,00 |
| подвал бүлмәләрен ремонтлау | кв.м | 631,00 |
| түбәне ремонтлау | кв.м | 34 177,96 |
| фасадны ремонтлау | кв.м | 11 700,00 |
| фасадны җылыту | кв.м | 75 423,50 |
| лифт җиһазларын алыштыру | штук | 2 |

5 бүлектә «2022 елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясауга финанс чаралары ихтыяҗы күләме» 2 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2022 елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясауга финанс чаралары ихтыяҗы күләме

Табл.№2

| Күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге: | Финанслау ихтыяҗы, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау, шул исәптән: | |
| җылылык белән тәэмин итү | 6 500 000,00 |
| электр белән тәэмин итү | 28 500 000,00 |
| подвал бүлмәләрен ремонтлау | 1 000 000,00 |
| түбәне ремонтлау | 128 250 000,00 |
| фасадны ремонтлау | 6 800 000,00 |
| фасадны җылыту | 171 900 000,00 |
| лифт җиһазларын алыштыру | 5 000 000 |
| Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 5 430 000,00 |
| Төзелеш контролен гамәлгә ашыру | 5 097 750,00 |
| Барлыгы: | 358 477 750,00 |

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе  А.М. Каюмов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ